РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

« 14 » 07 2021 г. № 537

Ютазы мунииипаль районы
Башкарма комитеты административ
комиссиясен оештыру, аның составын
һәм эш регламентын раслау турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр булдыру һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Ютазы район советы карары нигезендә, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Ютазы муниципаль районының административ комиссиясен төзергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

Ютазы муниципаль районының административ комиссиясе составын (1 нче кушымта);

Ютазы муниципаль районының административ комиссиясе эш регламентын (2 нче кушымта).

4. Ютазы муниципаль районының административ комиссиясе вәкаләтләре чоры әлеге административ комиссиянең беренче утырышы көненнән башлана һәм биш ел тәшкил итә.

5. «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршында административ комиссия төзү турында» Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 18 июнендәге 427-ИК номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга; Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясен төзү турында 2018 елның 18 июнендәге 427-ИК номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 10.04.2019 елдагы 320-ИК номерлы карарын; Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитетының «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июнендәге 532-ИК номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карарын; Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 31 июлендәге 532-ИК номерлы "№427-ИК номерлы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясен төзү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында” карарын; Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июнендәге 427-ИК номерлы «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясен төзү турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында "гы 11.11.2019 елдагы 833-ИК номерлы карарын; Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июнендәге 427-ИК номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында"гы карарын; Ютазы муниципаль районы №73-ИК «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 18.06.2018 елдан № 427-ИК «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясен төзү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында"гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Порталында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре http://jutaza.tatarstan.ru) мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче С.П. Самонина

1 нче санлы кушымта
Ютазы муниципаль районының
Башкарма комитеты
карарына
№ ____----________ __________

## Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссия составы

| | |
|---|---|
| Самонина Светлана Петровна | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Власова Оксана Александровна | Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Латыйпова Зөлфия Мөрсәлим кызы | Административ комиссиянең әйдәп баручы белгече, комиссиянең җаваплы секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Исмәгыйлева Тәслимә Габделбәр кызы | Урыссу ш.т.п. Башкарма комитетның әйдәп баручы белгече (килешү буенча) |
| Ширеева Эльвира Рамил кызы | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге әйдәп баручы белгече |

2 нче санлы кушымта
Ютазы муниципаль
районының
Башкарма комитеты
карарына
--
№ ________ _________

**Татарстан Республикасы**
**Ютазы муниципаль районы административ комиссиясе эш регламенты**

Әлеге регламент Ютазы муниципаль районының административ комиссиясе (алга таба - административ комиссия) эше тәртибен билгели.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ комиссия Татарстан Республикасының Ютазы район Советы тарафыннан төзелде.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) һәм Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Административ комиссия Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында кодексында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы чикләрендә эшли.

1.4. Административ комиссиянең бурычы булып административ хокук бозу турындагы һәр эшне һәрьяклап, тулы, объектив һәм вакытында карау, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы һәм Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, чыгарылган карарны үтәүне тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү тора.

1.5. Административ комиссиянең вәкаләтләр чоры әлеге административ комиссиянең 5 елга беренче утырышы көненнән башлана. Күрсәтелгән вакыт узганнан соң, административ комиссия яңа составтагы административ комиссиянең беренче утырышы көненә кадәр үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны дәвам итә.

1.6. Административ комиссия әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла.

1.7. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты административ комиссиянең үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан әгъзасы урынына административ комиссиянең яңа әгъзасын, административ комиссия әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, билгеләп куярга тиеш.

1.8. Административ комиссиянең аның тулы исеме язылган мөһере бар.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру

2.1. Административ комиссия административ комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, җаваплы сәркатиптән һәм административ комиссия әгъзаларыннан (алга таба - административ комиссия әгъзалары) тора, алар Ютазы муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

2.2. Административ комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашыралар.

2.3. Административ комиссиянең персональ һәм сан составы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан кимендә 5 кеше күләмендә билгеләнә һәм төгәл сан тәшкил итәргә тиеш.

2.4. Административ комиссия составына даими штат нигезендә административ комиссиянең җаваплы секретаре керә. Административ комиссиянең башка әгъзалары, әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган очраклардан тыш, иҗтимагый башлангычларда административ комиссиядә эшлиләр.

2.5. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча административ комиссиянең башка әгъзалары үз вазыйфаларын җирле бюджет акчалары исәбеннән даими түләүле нигездә башкара алалар.

2.6. Административ комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм административ комиссиянең җаваплы секретаре арасындагы вазыйфаларны бүлә, аларның функцияләрен Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә билгели.

2.7. Административ комиссия рәисе, административ комиссия әгъзаларының, шулай ук административ комиссия рәисе урынбасарының һәм җаваплы секретареның квалификациясен күтәрү эшен оештыра.

2.8. Административ комиссия килүчеләрне кабул итә ала. Килүчеләрне кабул итү тәртибе административ комиссия рәисе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

2.9. Административ комиссия адресына килгән шикаятьләр һәм гражданнар һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләре гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.

2.10. Административ хокук бозулар буенча эшләр административ комиссиядә саклана һәм 3 ел үткәч Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлегенә тапшырыла.

## 3. Административ комиссия утырышын чакыру һәм уздыру тәртибе

3.1. Административ хокук бозулар турында эшләрне карау Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә административ комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.2. Административ хокук бозулар турындагы эшләр утырышларда административ комиссия тарафыннан карала. Административ комиссия утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турындагы карар аның рәисе тарафыннан, ә ул булмаганда, административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән саен, аның рәисе урынбасары тарафыннан кабул ителә, ләкин аена 1 тапкырдан да ким түгел.

3.3. Административ комиссия утырышлары административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау срокларын үтәүне тәэмин итә торган вакыт аралыгы белән уздырыла.

3.4. Административ комиссиянең җаваплы секретаре административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм

урыны турында административ комиссия утырышын үткәргәнгә кадәр кимендә 2 көн кала хәбәр итә.

3.5. Административ комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм әгъзалары бу хакта административ комиссиянең җаваплы секретарена, кагыйдә буларак, административ комиссия утырышы көненә кадәр 1 эш көне кала хәбәр итәргә тиеш.

3.6. Әгәр административ комиссия утырышында административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы була.

3.7. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар, билгеләмә утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

## 4. Административ җәза салу турындагы карарны үтәү

4.1. Административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарлар Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә үтәлә.

4.2. Эш буенча производствода катнашучы затларның, башка физик һәм юридик затларның административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарларын, билгеләмәләрен һәм тәкъдимнәрен тикшереп торуны административ комиссиянең җаваплы секретаре гамәлгә ашыра.

## 5. Административ хокук бозуларны профилактикалау

5.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатларында, административ комиссия үз эшчәнлеген Федераль суд приставлары хезмәте идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән координацияли.

5.2. Административ комиссия күчмә утырышлар уздыра, шул исәптән, рәис раслаган график буенча, муниципаль район җирлегендә.

5.3. Административ комиссия профилактик эшне үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре уздыру юлы белән оештыра.